КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1326

2022 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2022 елга 18 563 887,9 мең сум күләмендә Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасын;

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында Казан шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча федераль бюджеттан 604 201,5 мең сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар рәвешендә кергән акча һәм 2 000 000,0 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында Яр Чаллы шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 360 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында Түбән Кама шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча 480 000,0 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән, 488 900,0 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 1 502 208,7 мең сум күләмендә субсидия рәвешендә кергән акча һәм 352 370,0 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасындагы «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасының гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл торак пунктларының иң якын иҗтимагый әһәмиятле объектларына, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып бара торган каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 402 459,5 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә кергән акча һәм 94 404,04 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

«Транспорт системасын үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Төбәк, муниципальара һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын үстерүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты чаралары кысаларында дәүләт күләмендәге һәм хосусый партнерлык механизмын кулланып тормышка ашырыла, федераль бюджеттан 5 000 000,0 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә кергән акча һәм 3 333 333,4 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

Татарстан Республикасының «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керә торган «Түбән Кама шәһәре» монопрофильле муниципаль берәмлегендә яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә юнәлдерелгән, 51 327,4 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

«Төбәк, муниципальара һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын үстерүгә булышлык күрсәтү» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына карата юл эшләренә юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 1 017 885,900 мең сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар рәвешендә кергән акча исәбеннән финанслана торган программаны;

«2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләренә керү юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән 300 000,0 мең сум күләмендәге программаны;

2. 2022 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләренең гомуми суммасы 35 550 978,34 мең сум тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Муниципаль юл фондларының 2022 елга җирле әһәмияттәге юлларда юл эшләренең муниципаль программаларын тормышка ашыруга кушымта нигезендә 1 250 200,0 мең сум күләмендә юнәлдерелә торган ассигнованиеләре күләмнәре турындагы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тәкъдимнәрен кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин